## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“28” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елнын 28 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- урамнарны чистарту, үлән чабу
- агачлар утырту, иске агачларны кисү
- өч фазалы генератор сатып алу, янгынга каршы гидрантлар урнаштыру, погружной насос сатып алу
- урам яктырту хезмәте күрсәтү, яктырткычлар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 251 (ике йөз илле бер) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 151 (йөз илле бер) кеше, бу 60,1 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 151 (йөз илле бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- урамнарны чистарту, үлән чабу
- агачлар утырту, иске агачларны кисү
- өч фазалы генератор сатып алу, янгынга каршы гидрантлар урнаштыру, погружной насос сатып алу
- урам яктырту хезмәте күрсәтү, яктырткычлар сатып алу

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гараев Х.Х.